БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ**
5 ноябрь 2019 ел

**КАРАР**
№ 212

**2019 елга һәм 2020-2021 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2018 елның 17 декабрендәге 158 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. «2019 елга һәм 2020-2021 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2018 елның 17 декабрендәге 158 номерлы (15.03.2019, 29.04.2019, 25.07.2019 үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2019 елга Балтач муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 940081,55 мең сум итеп;

2) Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 968042,82 мең сум итеп;

3) Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын 27961,27 мең сум итеп».

1.2. Карарның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны түбәндәгечә исәпкә алырга:

- әлеге карарның 18 нче кушымтасы нигезендә 2019 елда 643219,04 мең сум күләмендә;

- әлеге карарның 19 нчы кушымтасы нигезендә 2020 елда 521871,50 мең сум күләмендә һәм 2021 елда 525310,20 мең сум күләмендә.»

1.3. Карарның 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач муниципаль районы муниципаль хакимияте органнары 2019 елда һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорында, максатчан билгеләнешкә ия булган субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар хисабына финанслана торган очраклардан тыш, бюджет өлкәсенең муниципаль хезмәткәрләре һәм учреждениеләре һәм башка оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга, шулай ук

аларны карап тотуга чыгымнар китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

1.4. «2019 елга һәм 2020-2021 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2018 елның 17 декабрендәге 158 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарының 1 нче, 3 нче, 6 нчы, 8 нче, 10 нчы, 18 нче, 20 нче кушымталарын әлеге карарга 1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче, 5 нче, 6 нчы, 7 нче кушымталар нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин